ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 31.01.2024 132 **КАРАР**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз дип һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча ведомствоара комиссиясе төзү турында» 2020 елның 17 ноябрендәге 1089 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 6 апрелендәге 608 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 28 сентябрендәге 1708 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз дип һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча ведомствоара комиссиясе төзү турында» 2020 елның 17 ноябрендәге 1089 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.6 пунктындагы өченче абзацында «янгын сүндерү» сүзен төшереп калдырырга.

1.2. Нигезләмәнең 4.12 пунктындагы беренче абзацын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану өчен нигезләр булмау турында».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433

Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна

Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Э.Р.Әхмәдиева



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН